РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ КАРАР

25 ноябрь, 2024 ел № 29

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советының 2020 елның 17 февралендәге 6 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне электрон рәвештә сату тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советының 2020 елның 17 февралендәге 6 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне электрон рәвештә сату тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.1 пунктында «бәя игълан итмичә» сүзләрен «минималь рөхсәт ителә торган бәя буенча» сүзләренә алмаштырырга

1.2. Нигезләмәнең 1.3. пунктының «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Хосусыйлаштыру турында Федераль законда билгеләнгән очракларда мөлкәтне сатуның башлангыч бәясен, мөлкәтне гавами тәкъдим юлы белән сатканда беренчел тәкъдим бәясен һәм аны киметү бәясен, минималь рөхсәт ителгән бәядән сатуны уздырганда минималь бәяне, махсуслаштырылган аукцион уздырганда сатуның бердәм бәясен, «аукцион адымын», «киметү адымын» билгели.

1.3. Нигезләмәнең 2.3 пунктының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торышы канәгатьләнерлек булмаган социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларга, газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләрнең объектларына, елга порты объектларына карата ремонт һәм башка эшләр башкару;»

1.4. Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 2.5. пунктын өстәргә:

«2.5. Муниципаль мөлкәтне сату-алу шартнамәсендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

конкурс шартлары, аларны үтәү формалары һәм вакыты;

конкурста җиңүче тарафыннан конкурс шартларының үтәлешен раслау тәртибе;

конкурста җиңүченең конкурс шартларын үтәвен тикшерү тәртибе;

сату-алу шартнамәсе буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен якларның конкурста җиңүче тарафыннан шартларны үтәмәгән өчен неустойкасы рәвешендә, шулай ук аларны тиешенчә үтәмәгән өчен, шул исәптән, мондый шартларны үтәүнең аралык яисә соңгы срокларын һәм аларны үтәү күләмен бозган өчен муниципаль мөлкәт бәясе күләмендә җаваплылыгы;

Хосусыйлаштыру турында Федераль законның 29 статьясында мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларына карата каралган башка шартлар;

Хосусыйлаштыру турында Федераль законның 30.5 статьясында газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына карата каралган башка шартлар;

Хосусыйлаштыру турында Федераль законның 30.3 статьясында елга порты объектларына карата каралган башка шартлар;

якларның килешүе буенча билгеләнә торган башка шартлар.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресында бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев